СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2022 г. Агрыз № 23-5

«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 17.09.2022 елның 1015 номерлы "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елның 182 номерлы "Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләренең урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"карарына үзгәрешләр кертү турында" карары нигезендә Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Советының
26.10.2022 елның 20-8 номерлы
карары белән расланды (карар
редакциясендә 15.12. 2022
№23-5)

**«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр**

1. «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әгерҗе муниципаль районы Башлыгына, Әгерҗе муниципаль районы башлыгы урынбасарына, Әгерҗе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисенә айлык акчалата бүләкне билгеләргә:

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район башлыгы | 33592 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 30233 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 30233 |

»

2) Карарның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә вазыйфаи оклад билгеләргә:

| Вазыйфаның атамасы | Вазыйфаи окладның күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 32989 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 29690 |
| Совет аппараты җитәкчесе | 29944 |
| Башкарма комитет эшләре идарәчесе | 27787 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 29564 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 27153 |
| Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы бүлеге башлыгы | 23093 |
| Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы бүлеге башлыгы урынбасары | 20174 |
| Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органы секторы мөдире | 18652 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, район Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | 20174 |
| Совет, Башкарма комитет һәм башка җирле үзидарә органының баш белгече | 17891 |
| Советның, башкарма комитетның һәм башка җирле үзидарә органының әйдәп баручы белгече | 16622 |
| Башкарма комитетның 1 категорияле белгече | 15226 |

»

3) 6 пунктның 5 пунктчасында:
“1 процент” сүзләрен “18 процент” сүзләре белән алыштырырга.